ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.05.2020 г. Заинск № 222

**“2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 04 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 08 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. “2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын расларга (алга таба – Программа) (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсенә башка башкаручылар белән бергә программаның үтәлешен тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасына бюджетны формалаштырганда программаны гамәлгә ашыруга акчалар кертүне тәкъдим итәргә.
4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http//zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6.Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В.Чапковка йөкләргә.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист

И.З. Ашрапов

**“2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

## I. “2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | «2020 - 2022 елларга Зәй муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасы (алга таба – муниципаль программа) |
| Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | - «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 04 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- «2019-2021 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 05 мартындагы 159 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган дәүләт программасы;<br>- «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсен үстерү стратегиясен раслау турында» 2017 елның 20 июлендәге 473 номерлы Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы боерыгы;<br>- «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 2496 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары |

| | |
|---|---|
| Муниципаль заказчы (координатор) | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Муниципаль программаны төп эшләүче | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ (алга таба – «УФКСТ ЗМР РТ») |
| Муниципаль программаны башкаруда катнашучылар | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ<br>Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының “Барс” спорт мәктәбе” МБУ<br>Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының “Зәй” спорт мәктәбе” МБУ;<br>Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының “Олимпия чемпионы Ф.П.Симашев исемендәге олимпия резервы әзерләү спорт мәктәбе” МБУ |
| Муниципаль программаның максаты | Зәй муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру |
| Муниципаль программаның бурычлары | - массакүләм спортны үстерү;<br>- «Хезмәткә һәм оборонага әзер!» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кысаларында эшне оештыру;<br>- матди-техник базаны үстерү һәм ныгыту;<br>- югары казанышлар спортын үстерү, спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру;<br>- авыл җирлегендә физкультура-спорт эшен оештыру;<br>- физик культура һәм спорт өлкәсен кадрлар белән тәэмин итүне яхшырту |
| Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның сроклары һәм этаплары | Этапларга бүлми генә<br>2020-2022 еллар |
| Муниципаль программаны финанслау чыганаклары һәм күләмнәре | Муниципаль программаны финанслау Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты, билгеләнгән тәртиптә һәм бүлеп бирелгән күләмнәрдә республика бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылачак. |

| | |
|---|---|
| | Җирле бюджет:<br>2020 ел – 87500,8 мең сум;<br>2021 ел – 89883,9 мең сум;<br>2022 ел – 90495,9 мең сум.<br>Республика бюджеты:<br>2020 ел – 39 963,6 мең сум;<br>2021 ел–ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе буенча;<br>2022 ел–ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе буенча; |
| Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2022 елга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>халыкның гомуми санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлешен 53,7 процентка кадәр арттыру;<br>"Хезмәткә һәм оборонага әзер!" Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән Татарстан Республикасы гражданнарының "Хезмәткә һәм оборонага әзер!" Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын тапшыруда катнашкан халыкның гомуми өлешендә 30 процентка кадәр арту;<br>мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне физик тернәкләндерү һәм социаль адаптацияләү;<br>республика, бөтенроссия һәм халыкара ярышларда Зәй районы спортчыларының уңышлы катнашуын тәэмин итү;<br>спорт инфраструктурасын үстерү. |

## II. Муниципаль программа белән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләргә кыскача характеристика

Соңгы елларда Зәй муниципаль районында физик культура һәм спорт үсешендә уңай үзгәрешләр булды. Матди базаны үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә мәгълүмати ярдәм күрсәтү буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән актив эшләү Зәй районы халкын даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итүгә хезмәт итте.

2019 елда районның физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче халкының чагыштырма саны 1 процентка (47,8 проценттан 48,8 процентка кадәр) артты.

Безнең илдә һәм республикада физик культураны үстерү стратегиясе бурычларының берсе - 2024 елга спорт белән даими төстә шөгыльләнүгә гражданнарның кимендә 55 процентын җәлеп итү. Әлеге күрсәткечкә ирешү өчен физкультура-спорт эше түбәндәге юнәлешләр буенча оештырыла: беренче чиратта бу - балалар спорты:

мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә балалар белән дәресләр;

мәктәпләрдә физик культура дәресләре;

спорт мәктәпләрендә дәресләр;

студентлар спорты.

Районда 21 гомуми белем бирү мәктәбе, 18 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус (9нчы) мәктәп бар.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә физик культура буенча дәресләрне профильле белемгә ия 19 инструктор алып бара.

Спорт мәктәпләре базасында тренерларның нәфис гимнастика, хоккей, фигуралы шуу, чаңгыда узышу, футбол буенча шөгыльләнә торган берничә төркеме бар.

Ел дәвамында атна саен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә спорт залында, бассейнда, саф һавада физкультура дәресләре үткәрелә. Балалар һәм аларның әти-әниләре массакүләм спорт чараларында актив катнашалар. Шулай ук мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр «Татарстан чаңгы юлы», «Татарстан кроссы» спорт акцияләреннән, Физкультурачылар көне уңаеннан спорт бәйрәменнән дә читтә калмыйлар.

Гомуми белем бирү мәктәпләрендә 34 физик культура укытучысы эшли, шуларның 15е - авыл мәктәпләрендә.

Бүген безнең игътибар үзәгендә тугыз меңгә якын яшь зәйле (8920) тора, ә бу - районның төп стратегик ресурсы, кеше кыйммәтенең сыйфаты белем һәм тәрбия белән тыгыз бәйләнгән.

Гомуми белем бирү мәктәпләре территориясендә 13 универсаль спорт мәйданчыгы бар: алар 1нче (баскетбол-волейбол, футбол, хоккей), 5нче, 4нче, 6нчы, 3нче, 2нче (футбол) мәктәпләр, Сәвәләй, Чыбыклы, Аксар, Югары Шепкә һәм Бигеш (баскетбол-волейбол) авыл мәктәпләре территорияләрендә урнашкан.

Сәламәтлек саклау өлкәсендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып мәктәп спортын үстерү, балаларны һәм яшьләрне физик культура һәм спорт белән массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү тора.

Икенче юнәлеш - предприятие, оешма хезмәткәрләре һәм авыл яшьләре белән массакүләм физкультура эшен оештыру.

Предприятиеләрдә физкультура кадрлары белән тәэмин ителешкә килгәндә, «ТАТЭНЕРГО» АҖнең Зәй ГРЭСы филиалында (алга таба - Зәй ГРЭСы) 1 инструктор бар. Физкультура эшен оештыру белән барлык башка предприятиеләрдә үз бурычларыннан азат ителмәгән хезмәткәрләр шөгыльләнә.

Зәй ГРЭСында персоналны савыктыру, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм бу нигездә хезмәткәрләрнең нәтиҗәле хезмәт һәм башка эшчәнлек төрләренә әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Спорт-сәламәтләндерү эше расланган календарь план нигезендә гамәлгә ашырыла. Профсоюз комитеты каршында спорт-сәламәтләндерү эше буенча комиссия төзелгән һәм эшли, ә структур бүлекчәләрдә җаваплы затлар билгеләнгән. Аларның төп бурычы персоналны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә максималь дәрәҗәдә җәлеп итү. Әлеге максатларда станциядә ел саен 9 спорт төре буенча Спартакиада уздырыла: болар - шахмат, чаңгы узышы, өстәл теннисы, кросс, мини-футбол, пневматик винтовкадан ату, волейбол, йөзү.

Эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең яшәү урыны буенча физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен гомуми белем бирү мәктәпләренең спорт корылмалары файдаланыла. Кайбер учреждениеләр һәм оешмалар спорт корылмаларын арендага ала.

Предприятие һәм оешмалар коллективлары командалары Җиңү көненә, Шәһәр көненә, Татарстан Республикасы көненә, Физкультурачылар көненә, Бөтенроссия «Татарстан кроссы», «Россия чаңгы юллары» акцияләрендә катнаша.

Ел дәвамында шәһәрнең спорт объектларында предприятие, оешма һәм учреждение командалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасы уздырыла. Ярышларда 20 команда катнаша, алар арасында шәһәрнең эре предприятиеләре (Зәй ГРЭСы, «АккурайдУилзРуссия» ҖЧҖ, «ТЕХНО Заводы») командалары да, шулай ук сәламәтлек саклау, мәгариф, хокук саклау органнары җыелма командалары да бар. Барлыгы программага спортның 16 төре буенча 22 ярыш кертелгән. Ярышлар йомгаклары буенча 2019 елда командалар арасында 1 урынны Зәй ГРЭСы, 2 урынны - «ТЕХНО заводы», 3 урынны «АккурайдУилзРуссия» ҖЧҖ алды.

Муниципаль хезмәткәрләрне физик яктан камилләштерү, Татарстан Республикасы территориясендә физкультура-спорт хәрәкәтен саклап калу һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатларында ел саен Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре Спартакиадасы уздырыла, анда безнең районның муниципаль хезмәткәрләренең спорт төрләре буенча җыелма командалары да актив катнаша.

Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре Спартакиадасы йомгаклары буенча 2019 елда Зәй районы җыелма командасы республика буйсынуындагы үзәк шәһәр һәм шәһәр округлары булган муниципаль районнар арасында 3 урын алды.

Зәй муниципаль районы составына 22 авыл җирлеге керә, аларның территорияләрендә 76 спорт корылмасы, шул исәптән 6 футбол кыры, 7 хоккей тартмасы, гомумбелем бирү мәктәпләрендә 19 спорт залы, 6 универсаль спорт мәйданчыгы бар.

Иң мөһим проблемаларның берсе - авыл администрацияләре штатында халык белән физкультура-спорт эшен оештыручы белгеч булмау. Мондый белгечнең булмавы халыкны физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү эшен тиешенчә оештырмауга да йогынты ясый.

Зәй районы авыл җирлекләрендә 14 гомуми белем бирү, 5 урта белем бирү, 9 төп гомуми белем бирү мәктәбе бар, аларда 798 укучы исәпләнә.

Спорт мәктәпләренең тренерлары Поручик авылы (көрәш), Сәвәләй авылы (көрәш, гер спорты), Сармашбаш авылы (көрәш), Түбән Биш авылы (көрәш), Югары Шепкә авылы (чаңгы ярышлары), Бигеш авылы (бадминтон), Кадер авылы (көрәш, хоккей) мәктәпләре базасында дәресләр үткәрә.

Өлкәннәр арасында халыкның хәрәкәт активлыгын арттыру, физик культура һәм спортны популярлаштыру, ял итүнең төп формалары буларак, шулай ук иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау максатыннан, 2016 елдан башлап авыл җирлекләре арасында «Сәламәтлек» спартакиадасы киңәйтелгән форматта уздырыла. Ярышларда җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләүнең төрле формалары кулланылды: спорт мәйданчыклары төзү, спорт инвентаре алу өчен сертификатлар белән бүләкләү; 2018 елда һәм агымдагы елда шәхси беренчелектә җиңүчеләргә дә призлар тапшырылды.

2019 елда программага 15 спорт төре буенча 17 ярыш кертелгән иде: болар - чаңгы ярышлары, волейбол, ир-атлар һәм хатын-кызлар командалары арасында, кул көрәше, мини-лапта, шашка, спорт гаиләләре ярышлары, җиңел атлетика, спорт туризмы, бадминтон, шахмат, мини-футбол, ирләр һәм хатын-кызлар командалары арасында баскетбол, өстәл теннисы, йөзү, гер спорты. 2019 елгы Спартакиада нәтиҗәләре буенча 1 урынны Сәвәләй авыл җирлеге, 2 урынны Багraж авыл җирлеге, 3 урынны Поручик авыл җирлеге алды.

Спартакиаданы үткәрүнең төп бурычлары - авыл халкын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү һәм Татарстан

Республикасы авыл районнары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасында һәм «Авыл яшьләре» җәйге авыл спорт уеннары финалында катнашу өчен Зәй районы командасын формалаштыру.

Узган ел 10-15 сентябрь көннәрендә Актаныш авылында “Авыл яшьләре” Татарстан Республикасы XI җәйге авыл спорт уеннарының финал ярышлары узды. Зәй муниципаль районы җыелма командасы районнар арасында республика әһәмиятендәге шәһәрләргә кергән шәһәр җирлеге статусында 2 нче урын алды.

Татарстан Республикасы муниципаль районнары командалары арасында республика әһәмиятендәге шәһәрләргә караган шәһәр җирлеге статусында (2 төркем) Татарстан Республикасы «Сәламәтлек» XVI авыл спартакиадасында (2 төркем) гомумкоманда зачетында 2019 елның гыйнвар-декабрь айларында спортның 13 төре буенча Татарстан Республикасының район үзәкләрендә һәм кече шәһәрләрендә узган ярышларда Зәй муниципаль районы  2 урын алды.

Бүгенге көндә авыл җирлекләре командаларын спорт инвентаре һәм экипировка белән тәэмин итү зарурлыгы бар.

Өченче юнәлеш - өлкән буын вәкилләре белән физкультура-массакүләм эш һәм сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикле гражданнар белән ярышлар оештыру.

Районда барлыгы 3138 инвалид кеше исәпләнә, шуларның 192се – балалар, 1260ы - пенсионер. Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны - 600 кеше, бу гомуми санның 19 процентын тәшкил итә.

Адаптив спорт өлкәсендә эш “Шатлык” халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе базасында алып барыла. Спорт учреждениеләре: бассейн, боз сарае, тренажерлар залларына Зәй шәһәренең мөмкинлекләре чикләнгән кешеләре ел дәвамында бушлай йөри.

Командалар Татарстан Республикасы инвалидларының физкультура-спорт җәмгыяте һәм спортның адаптив төрләре республика инклюзив фестивалендә үткәрелә торган спорт ярышларында катнашалар. Муниципаль берәмлектә үстерелә торган спорт төрләре булып өстәл теннисы, шахмат, шашка, кул көрәше, йөзү тора. Ярышларга йөртү җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла.

Зәй муниципаль районының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе район инвалидлар җәмгыяте белән берлектә ел саен йөзү, шашка, шахмат, дартс, өстәл теннисы буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында ярышлар үткәрә.

Өлкән яшьтәге кешеләр «Татарстан чаңгы юлы», «Татарстан кроссы» спорт акцияләрендә, Физкультурачы көнендә, «Раштуа чаңгы ярышы» традицион кышкы ярышларда, волейбол, футбол, баскетбол, шахмат һәм шашка ярышларында актив катнашалар. «Пульс» һәм «Өмет» өлкәннәр клубы әгъзалары активлык күрсәтә. Өлкән буын арасында йөзү, чаңгы, шахмат, җиңел атлетика ярышлары аеруча популяр.

«Энергия» стадионы базасында шахмат клубы эшли, анда 20гә якын кеше йөри. «Энергетик» мәдәният сараеның спорт залында атнага 2 тапкыр «Өмет» өлкәннәр клубы дәресләре уза, анда 50ләп кеше йөри.

Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе ел саен пенсионерлар арасында шахмат һәм шашка буенча темпо - турнир һәм “Өченче буын” пенсионерлар Спартакиадасының муниципаль этапларын үткәрә, көчлеләр республика ярышларына сайлап алына.

Спорт инфраструктурасын үстерү һәм эзлекле камилләштерү өлкәсендә уңай динамика күзәтелә. 2019 ел ахырына Зәй муниципаль районында 192 спорт корылмасы эшләде.

Зәй муниципаль районында булдырылган спорт инфраструктурасы төрле яшьтәге меңләгән гражданга физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнергә мөмкинлек бирә.

Биш ел эчендә районның спорт объектларын ремонтлау һәм реконструкцияләүгә шактый финанс чаралары кертелде: 2014 елда Сәламәтлек мәктәбенә 26 229 873, 61 сумлык ремонт ясалды; 2016 елда «Ялта-Зәй» спорт комплексында чаңгы-роллер трассасы төзелешенә 88 млн. сум акча сарыф ителде; 2014 елда башланган «Энергия» стадионын реконструкцияләүгә 2017 елда 73308,6 мең сум акча кертеп, ул төгәлләнде, шулай ук 2017 елда Олимпия чемпионы Федор Петрович Симашев исемендәге спорт мәктәбе бинасына 37, 7 млн. сумлык капиталь ремонт ясалды; 2017 елда «Энергетик» мәдәният сараена капиталь ремонт кысаларында спорт залы ремонтланды, хәзер анда өстәл теннисы белән шөгыльләнү өчен зал эшли.

Республика программасын тормышка ашыру кысаларында Зәй муниципаль районында универсаль спорт мәйданчыклары төзү дәвам итә. 2019 елда районда Югары Шепкә һәм Бигеш төп гомуми белем бирү мәктәпләре территориясендә ике спорт мәйданчыгы төзелде.

2013 елдан 2019 елга кадәр районда 52 329 мең сумлык 22 универсаль спорт мәйданчыгы төзелде. «Барлык категория һәм халык төркемнәре өчен физик культура һәм спорт, массакүләм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, шул исәптән спорт объектлары белән тәэмин ителеш

дәрәҗәсен арттыру, шулай ук спорт резервын әзерләү» (спорт – тормыш нормасы) федераль проекты кысаларында «Демография» милли проекты белән «Энергия» стадионында 3 468 136 сумлык «Хезмәткә һәм оборонага әзер!» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәүгә әзерләнү өчен тренажерлар белән спорт мәйданчыгы төзелде.

2020 елда шәһәрнең иң эре спорт объектларының берсе - 4388,3 квадрат метр мәйданлы, составына универсаль спорт залы, 4 юллы йөзү бассейны керә торган спорт-сәламәтләндерү комплексы капиталь ремонтланачак. Моның өчен Министрлар Кабинетының 2019 елның 11 декабрендәге 3204-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан 39 987,6 мең сум күләмендә финанс чаралары бүлеп бирелде.

Шулай ук футбол буенча ел дәвамында сыйфатлы тренировкалар уздыру өчен мини-футбол кыры белән ябык футбол манежы төзү дә кирәк.

Районда физкультура-спорт юнәлешендәге 4 учреждение эшли, аларның 3се - спорт мәктәбе (алга таба - СМ), 1се - олимпия резервы спорт мәктәбе (алга таба-ОРСМ). Аларда 2453 кеше шөгыльләнә, 19 спорт төре буенча дәресләр алып барыла.

Спорт учреждениеләре хезмәткәрләре саны 220 кеше (шуларның 34е-берьюлы ике эшне алып бара), 43 тренер (шуларның 24е берьюлы ике эш алып бара). Квалификацияле тренерлар һәм методик кадрларның җитмәве проблемалы мәсьәлә булып тора.

Хәзерге вакытта 2020-2022 елларга Зәй муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре чагылырга тиешле муниципаль программаны эшләү һәм раслау зарурлыгы туды.

Муниципаль программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, халыкның барлык яшь төркемнәренең физик активлыгын һәм әзерлеген арттыруга, тулы канлы ял һәм сәламәт ял өчен шартлар тудыруга, спорт резервын әзерләүгә һәм Зәй муниципаль районы спортчыларының республика, Россия һәм халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясауларына юнәлтелгән чараларны башкаруны күздә тота.

## III. Муниципаль программаның төп максаты һәм бурычлары

Программаның максаты - Зәй муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру.

Куелган максатны тормышка ашыру процессы түбәндәге бурычларны хәл итүне үз эченә ала:

- массакүләм спортны үстерү;
- «Хезмәткә һәм оборонага әзер!" Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кысаларында эшне оештыру;
- матди-техник базаны үстерү һәм ныгыту;
- югары казанышлар спортын үстерү, спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру;
- авыл җирлегендә физкультура-спорт эшен оештыру;
- физик культура һәм спорт өлкәсен кадрлар белән тәэмин итүне яхшырту.

Программа сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, халыкның барлык яшь төркемнәренең физик активлыгын һәм әзерлеген арттыруга, тулы канлы ял һәм сәламәт ял өчен шартлар тудыруга, спорт резервын әзерләүгә һәм республика, Россия һәм халыкара спорт ярышларында Зәй спортчыларының уңышлы чыгыш ясауларына юнәлдерелгән чараларны башкаруны күздә тота.

## IV. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Муниципаль программа, этапларга бүлмичә генә, 2020-2022 елларга исәпләнгән.

## V. Муниципаль программаны финанс белән тәэмин итү

Муниципаль программаны финанслау Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты һәм билгеләнгән тәртиптә бүлеп бирелгән күләмнәрдә республика бюджеты чаралары хисабына башкарылачак.

Җирле бюджет:
2020 ел – 87500,8 мең сум;
2021 ел – 89883,9 мең сум;
2022 ел – 90495,9 мең сум.
Республика бюджеты:
2020 ел – 39 963,6 мең сум;
2021 ел – ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе буенча;
2022 ел – ТР Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе буенча.

## VI. Муниципаль программаны тормышка ашыру механизмы

Муниципаль программаның координаторы һәм җаваплы башкаручысы - "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе" МКУ.

"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт идарәсе" МКУ программа чаралары

исемлеген, аларны тормышка ашыру чыгымнарын төгәлләштерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәрне; максатчан индикаторлар исемлеген һәм аларны квартал саен бүлүне төгәлләштерүне; муниципаль программаны гамәлгә ашыруның барышы турында ел саен хисапны әзерли.

## VII. Муниципаль программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү хисап елында фактта ирешелгән күрсәткечләрне (индикаторларны) чагыштыру юлы белән муниципаль программа максатларына ирешү дәрәҗәсен бәяләү һәм бурычларны хәл итү нигезендә үткәрелә.

Муниципаль программаның иң мөһим социаль-икътисадый нәтиҗәсе физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр санын арттыру булачак, нәтиҗәдә бу район халкының сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итәчәк.

Спортны үстерү нәтиҗәсендә спортчыларның төрле дәрәҗәдәге ярышларда уңышлы чыгыш ясаулары өчен югары квалификация дәрәҗәсе күтәреләчәк.

Зәй муниципаль районы халкының төрле категорияләрен физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнү процессына киң җәлеп итү наркомания, алкоголизм, тәмәке тарту һәм башка зарарлы гадәтләрне, авыруларны киметүгә, эшкә сәләтлелекне арттыруга һәм район халкының гомер озынлыгын арттыруга ярдәм итәчәк.

Муниципаль программаның бюджет нәтиҗәлелеге физик культура һәм спорт өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыру кысаларында чараларга юнәлдерелгән чыгымнарның нәтиҗәлелеген күтәрүдән гыйбарәт.

Муниципаль программаны гамәлгә ашырудан экологик нәтиҗәлелек түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- үсеп килүче яшь буынны һәм яшьләрне әхлакый тәрбияләүдә, шул исәптән әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләүдә;
- хуҗалык әйләнешендә файдаланылмаган җирләрне спорт мәйданчыклары итеп файдалануда.

Төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук муниципаль программа чаралары кысаларында финанслау күләмнәре 1нче таблицада бирелгән.

Таблица 1

## "2020-2020 елларга Зәй муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Төп чараларның исемнәре | Башкаручылар | Чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның күрсәткече, елларга бүлеп | | | | Финанслау, мең сумнарда. | | | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | База елы | 2020 | 2021 | 2022 | 2020 | 2021 | 2022 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| **Массакүләм спортны үстерү** | | | | | | | | | | | |
| Төрле категория халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | Халыкның гомуми саныннан чыгып, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче гражданнарның өлешен арттыру, (%) | 48,8 | 50,1 | 52,5 | 53,7 | - | - | - | - |
| | | | 3-6 | 95 | 95 | 95 | 96 | | | | |
| | | | 7-18 | 95 | 95 | 95 | 96 | | | | |
| | | | 19-29 | 41 | 42 | 43 | 44 | | | | |
| | | | 30-45 | 41 | 42 | 43 | 44 | | | | |
| | | | 46-60 | 41 | 42 | 43 | 44 | | | | |
| | | | 61-69 | 39 | 40 | 41 | 42 | | | | |
| | | | 70 һәм аннан өлкән | 21 | 22 | 23 | 24 | | | | |
| Барлык яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар турнирлары һәм массакүләм ярышлар үткәрү | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны | 93 | 104 | 112 | 120 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар саны, кеше | 5580 | 6000 | 6480 | 6900 | | | | |
| Барлык яшь категорияләре арасында спорт-масса чаралары | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны | 5 | 5 | 5 | 5 | 400,0 | 400,0 | 400,0 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар саны, | 7200 | 7400 | 7600 | 7800 | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| үткәрү | | | кеше | | | | | | | | |
| Предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр командалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасын үткәрү | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны | 22 | 22 | 22 | 22 | 232,0 | 232,0 | 232,0 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар саны | 869 | 940 | 1010 | 1060 | | | | |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән гражданнар һәм өлкән буын гражданнары арасында спорт ярышлары, спартакиадалар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре үткәрү, республика ярышларында катнашу | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр арасында үткәрелгән чаралар саны | 4 | 8 | 12 | 16 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Җирле бюджет |
| | | | Өлкән буын арасында үткәрелгән чаралар саны | 4 | 11 | 15 | 19 | | | | |
| | | | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән катнашучылар саны | 40 | 80 | 120 | 160 | | | | |
| | | | Өлкән буын вәкилләре саны | 45 | 220 | 300 | 380 | | | | |
| **«Хезмәткә һәм оборонага әзер!» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кысаларында эш оештыру** | | | | | | | | | | | |
| «Хезмәткә һәм оборонага әзер!» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын барлык яшь категорияләре арасында сынап карау | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | ГТО нормаларын тапшырырга теркәлүчеләр өлеше, халыкның гомуми санынннан (%) | 18,79 | 24 | 25 | 26 | - | - | - | - |
| | | | ГТО комплексы сынаулары (тестлары) нормативларын үтәүдә катнашучылар өлеше, халык санынннан, (%) | 13,35 | 18 | 19 | 20 | | | | |
| | | | Сынаулар | 27 | 28 | 29 | 30 | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | нормативларын билгеләргә үтәүчеләр өлеше сынауларга керешүчеләр саныннан, (%) | | | | | | | | |
| | | | Халык саныннан сынау нормативларын билгеләргә үтәүчеләр өлеше, (%) | 7,52 | 8 | 8,5 | 9 | | | | |
| **Матди-техник базаны үстерү һәм ныгыту** | | | | | | | | | | | |
| Спорт-савыктыру комплексына капиталь ремонт | УФКСиТ СШ «Зай» Отдел ЖКХ | 2020-2021 | | | | | | 39 963 ,6 | ТР МК курс. буенча | - | Республика бюджеты |
| Универсаль спорт мәйданчыклары төзү | УФКСиТ Отдел ЖКХ | Ел саен | | | | | | по РКМ РТ | - | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |
| Мини-футбол кыры булган ябык футбол манежы төзү | УФКСиТ Отдел ЖКХ | 2021 | | | | | | - | ТР МК курс. буенча | - | Республиканский бюджеты |
| **Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру** | | | | | | | | | | | |
| Спорт мәктәпләрен тоту | СШ СШОР | Ел саен | - | - | - | - | - | 83395,5 | 86883,9 | 87495,9 | Җирле бюджет |
| Спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазландыру өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | - | - | - | - | - | 757,2 | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |
| ТР Зәй муниципаль районының «Яшьлек» спорт мәктәбе» МБУдә хоккейны үстерү | СШ «Яшьлек» | Ел саен | - | - | - | - | - | 348,1 | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренеларга, шулай ук муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | - | - | - | - | - | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |
| Физкультура-спорт оешмаларының яшь белгечләренә-хезмәткәрләренә айлык кызыксындыру өстәмә түләве | УФКСиТ СШ СШОР | ежегодно | - | - | - | - | - | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | ТР МК курс. буенча | Республика бюджеты |
| Югары спорт осталыгына әзерләү һәм спорт осталыгын камилләштерү этапларында медицина контролен һәм спортчыларны тикшерүне тәэмин итү | СШ СШОР | ежегодно | кеше | | 50 | 50 | 50 | - | 50,0 | 50,0 | Җирле бюджет |
| Календарь план нигезендә спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрнең рәсми ярышларда катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ СШ | ежегодно | | | | | | 1 050,0 | 1 000,0 | 1 000,0 | Җирле бюджет |
| Календарь план нигезендә ир-атлар һәм хатын-кызлар җыелма командаларының рәсми ярышларда катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ | | | | | | | 825,1 | 825,1 | 825,1 | Җирле бюджет |
| Спортчыларның физик әзерлеге һәм спорт осталыгы дәрәҗәсен | СШ СШОР | ежегодно | Разрядлы спортчылар саны, кеше: | | | | | - | - | - | - |
| | | | МС | 1 | 2 | 2 | 2 | - | - | - | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| күтәрү | | | КМС | 11 | 12 | 14 | 15 | - | - | - | |
| | | | 1 разряд | 20 | 22 | 24 | 26 | - | - | - | |
| | | | Ярышларда призерлар саны, кеше: | | | | | - | - | - | |
| | | | ТР беренчелеге | 60 | 65 | 70 | 75 | - | - | - | |
| | | | РФ беренчелеге | 7 | 8 | 9 | 10 | - | - | - | |
| | | | ТР чемпионаты | 10 | 12 | 14 | 15 | - | - | - | |
| | | | РФ чемпионаты | 3 | 3 | 3 | 3 | - | - | - | |
| | | | Численность членов сборных команд: | | | | | - | - | - | |
| | | | ТР | 31 | 32 | 33 | 34 | - | - | - | |
| | | | РФ | 9 | 10 | 10 | 10 | - | - | - | |
| **Авыл җирлегендә физкультура-спорт эшен оештыру** | | | | | | | | | | | |
| Авыл җирлекләре командалары арасында «Сәламәтлек " спартакиадасы үткәрү | УФКСиТ СШ СШОР | Ел саен | Үткәрелә торган ярышлар саны | 24 | 24 | 24 | 24 | 342,9 | 342,9 | 342,9 | Җирле бюджет |
| | | | Катнашучылар санын арттыру, кеше | 848 | 1015 | 1060 | 1110 | | | | |
| Район җыелма командаларының Татарстан Республикасы «Сәламәтлек» спартакиадасында катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ | Ел саен | - | - | - | - | - | - | - | - | Җирле бюджет |
| Район җыелма командасының «Авыл яшьләре " җәйге авыл уеннары финалында катнашуын тәэмин итү | УФКСиТ | 2 елга бер мәртәбә | - | - | - | - | - | - | - | - | Җирле бюджет |
| **Физик культура һәм спорт өлкәсен кадрлар белән тәэмин итүне яхшырту** | | | | | | | | | | | |
| Физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрне әзерләүне һәм яңадан әзерләүне оештыру | УФКСиТ СШОР | Ел саен | Тренер кадрларының квалификациясен күтәрү | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Массакүләм спорт эшен планлаштыру тәҗрибәсен уртаклашу һәм гомумиләштерү буенча семинарлар, ачык | УФКСиТ | Ел саен | | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| дәресләр, киңәшмәләр үткәрү | | | | | | | | | | | |
| Югары спорт нәтиҗәләренә ирешкән спортчылар арасыннан өлкән сыйныф укучылары белән һөнәри юнәлеш бирү эшен алып бару һәм махсус уку йортларына кергәндә аларга ярдәм күрсәтү. | УФКСиТ<br>СШ<br>СШОР | Ел саен | | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Ярышларга хезмәт күрсәтү өчен спорт судьяларын әзерләү һәм яңадан әзерләү буенча семинарлар үткәрү | УФКСиТ<br>СШ<br>СШОР | Ел саен | | - | - | - | - | | | | - |